**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

12 ноябрь, 2019 ел | Мәләкәс авылы | № 24

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Мәләкәс авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 23 ноябренә 15:00 сәгатьтә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Мәләкәс авылында Көнчыгыш, Елга урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Мәләкәс авылы, Үзәк ур., 27А й. (авыл клубы бинасы) янында билгеләргә.

2. 2019 елның 23 ноябренә 17:00 сәгатьтә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Мәләкәс авылында Үзәк , Яшьләр , Мәктәп урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Мәләкәс авылы, Үзәк ур., 27А й. (авыл клубы бинасы) янында билгеләргә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Мәләкәс авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) тротуарлар төзү;

2) Мәләкәс авылына керү юлында урам яктырткычларын урнаштыру;

3) энергия саклый торган лампалар сатып алу һәм урнаштыру;

4) юлларны ремонтлау;

5) Мәләкәс елгасы аша җәяүлеләр күперен ремонтлау өчен материаллар сатып алу һәм ремонтлау;

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Мәләкәс авылы, Үзәк урам, 27А.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы В.И. Артемьев